| БАВЛИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

11.04.2022 ел Баулы шәһәре № 56

«Баулы шәһәре» муниципаль
берәмлеге бюджеты үтәлеше
турында» Баулы шәһәр Советының
2021 елгы карары проекты хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «2021 елда “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында» Баулы шәһәр Советы карары проектын (1нче кушымта) хупларга һәм фикер алышуга куярга, шул исәптән ачык тыңлауларга чыгарырга.

2. 1 нче кушымта нигезендә карар проектын беренче укылышта кабул итәргә.

3. Түбәндәгеләрне расларга:

- гражданнарның «2021 елда «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында» Баулы шәһәр Советы карары проекты буенча тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибен (2 нче кушымта);

- «2021 елда «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында» Баулы шәһәр Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар уздыру тәртибен (3нче кушымта).

4. http//pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга:

«2021 елда «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында» Баулы шәһәр Советы карары проектын (1нче кушымта);

- гражданнарның «2021 елда «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында» Баулы шәһәр Советы карары проекты буенча тәкъдимнәрен исәпкә

алу һәм аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибен (2нче кушымта);

- «2020 елда «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында» Баулы шәһәр Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар уздыру тәртибен (3нче кушымта).

5. «2021 елга «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында» Баулы шәһәр Советы карары проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эш төркемен түбәндәге составта төзергә:

1. Тимофеев Станислав Николаевич - эш төркеме рәисе.

2. Васиков Риф Ринат улы - эш төркеме әгъзасы.

3. Свежинкина Лилия Салихҗан кызы - эш төркеме әгъзасы.

6. «2021 елда «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында» Баулы шәһәр Советы карары проекты буенча ачык тыңлауларны 2022 елның 28 апрелендә 16.00 сәгатьтә Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының утырышлар залында (Татарстан Республикасы, Баулы районы, Баулы шәһәре, Куйбышев ур., 20 йорт) уздырырга.

7. Эш төркеменә «2021 елда «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында» Баулы шәһәр Советы карары проекты буенча Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советы депутатларының һәм гражданнарның тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә һәм Баулы шәһәр Советы каравына чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «2021 елда «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында» Баулы шәһәр Советы карары проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эш төркеменә йөкләргә.

Баулы шәһәре Мэры урынбасары,
шәһәр Советы Рәисе урынбасары К.Ф. Корбанов

Татарстан Республикасы
Баулы шәһәр Советының
2022 елның 11 апрелендәге
56 номерлы карарына
1нче кушымта

«2021 елда «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге
бюджеты үтәлеше турында» Баулы шәһәр Советы карары
ПРОЕКТЫ

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге уставына һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегендә бюджет корылышы турында нигезләмәгә таянып, Баулы шәһәр Советы

КАРАР ИТТЕ:

2021 елда «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турындагы хисапны керемнәр буенча 145 502,3 мең сум күләмендә, чыгымнар буенча 122 565,1 мең сум күләмендә (22 937,2 мең сум профицит белән) һәм түбәндәге күрсәткечләр белән расларга:

әлеге карарга 1нче кушымта нигезендә, бюджетлар керемнәре классификациясе кодлары буенча 2021 елда «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәрен;

әлеге карарга 2нче кушымта нигезендә, бюджет чыгымнарының ведомство структурасы буенча 2021 елда «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарын;

әлеге карарга 3нче кушымта нигезендә, бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча 2021 елда «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарын;

әлеге карарга 4нче кушымта нигезендә, бюджетлар кытлыгын финанслау чыганаклары классификациясе кодлары буенча 2021 елда «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын.

Татарстан Республикасы
Баулы шәһәр Советының
2022 елның 11 апрелендәге
56 номерлы карарына
1нче кушымта

**2021 елга бюджетлар керемнәре классификациясе кодлары буенча «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәре**

(мең сум)

| Күрсәткеч атамасы | Бюджет классификациясе коды | | Касса башкаруы |
|---|---|---|---|
| | Керемнәр администраторы | «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәре | |
| **Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе** | **182** | | **98 379,6** |
| Салым исәпләү һәм түләү Россия Федерациясе Салым кодексының 227, 227 1 һәм 228 статьялары нигезендә гамәлгә ашырыла торган керемнәрдән тыш, чыганагы салым агенты булган керемнәрдән физик затлар керемнәренә салым | 182 | 1 01 02010 01 0000 110 | 35 002,2 |
| Россия Федерациясе Салым кодексының 227 статьясы нигезендә индивидуаль эшкуарлар, хосусый практика белән шөгыльләнүче нотариуслар, адвокат кабинетларын гамәлгә куйган адвокатлар һәм хосусый практика белән шөгыльләнүче башка затлар буларак теркәлгән физик затлар эшчәнлеген гамәлгә ашырудан алынган керемнәрдән физик затлар керемнәренә салым | 182 | 1 01 02020 01 0000 110 | 115,6 |
| Россия Федерациясе Салым кодексының 228 статьясы нигезендә физик затлар алган керемнәрдән физик затлар керемнәренә салым | 182 | 1 01 02030 01 0000 110 | 277,6 |
| Салым базасы өлешенә карый торган 650 000 сумнан артыграк салым суммасында физик затлар керемнәренә салым | 182 | 1 01 02080 01 0000 110 | 22 999,5 |
| Бердәм авыл хуҗалыгы салымы | 182 | 1 05 03010 01 0000 110 | 213,7 |
| Шәһәр җирлекләре чикләрендә урнашкан салым салу объектларына карата кулланыла торган ставкалар буенча алына торган физик затлар мөлкәтенә салым | 182 | 1 06 01030 13 0000 000 | 8 095,0 |
| Шәһәр җирлекләре чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенә ия булган оешмалардан җир салымы | 182 | 1 06 06033 13 0000 110 | 25 553,2 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Шәһәр җирлекләре чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенә ия булган физик затлардан җир салымы | 182 | 1 06 06043 13 0000 110 | 6 123,8 |
| Шәһәр җирлекләре территорияләрендә туплана торган җир салымы (2006 елның 1 гыйнварына кадәр барлыкка килгән йөкләмәләр буенча) | 182 | 1 09 04053 13 0000 110 | -2,1 |
| 2020 елның 1 гыйнварына кадәр барлыкка килгән бурычларны каплау исәбенә керә торган акчалата түләтүләрдән (штрафлардан) 2019 елда гамәлдә булган нормативлар буенча муниципаль берәмлек бюджетына күчерелергә тиеш керемнәр | 182 | 1 16 10123 01 0000 140 | 1,1 |
| **Баулы муниципаль районының финанс-бюджет палатасы** | **803** | | **44 143,9** |
| Куркыныч, авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы йөкләрне ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чараларын автомобиль юллары буйлап хәрәкәткә махсус рөхсәт биргән өчен җирлекнең җирле үзидарә органы тарафыннан җирлекләр бюджетларына күчерелә торган дәүләт пошлинасы | 803 | 1 08 07175 01 0000 110 | 20,5 |
| Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе субъектлары законнарында билгеләнгән административ штрафлар | 803 | 1 16 02020 02 0000 140 | 17,3 |
| муниципаль хокукый актларны үтәмәгән өчен Бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә шәһәр җирлекләре бюджетларына дотацияләр | 803 | 2 02 16001 13 0000 150 | 4 404,1 |
| Башка дәрәҗәдәге хакимият органнары тарафыннан кабул ителгән карарлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен шәһәр җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар | 803 | 2 02 45160 13 0000 150 | 39 702,0 |
| **"Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы" МКУ** | **804** | | **2 978,8** |
| Дәүләт милке чикләнмәгән һәм шәһәр җирлекләре чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре өчен аренда түләве рәвешендә алына торган керемнәр, шулай ук күрсәтелгән җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәләрен төзү хокукын сатудан акчалар | 804 | 1 11 05013 13 0000 120 | 2 494,4 |
| Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары, дәүләт яисә муниципаль предприятиеләр йә дәүләт милке чикләнмәгән һәм шәһәр җирлекләре чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренә карата дәүләт яисә муниципаль учреждениеләр тарафыннан төзелгән сервитут билгеләү турындагы килешүләр буенча түләү | 804 | 1 11 05313 13 0000 120 | 0,1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Дәүләт милке чикләнмәгән һәм шәһәр җирлекләре чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен сатудан керемнәр | 804 | 1 14 06013 13 0000 430 | 484,3 |
| **Барлыгы керемнәр** | | | **145 502,3** |

Татарстан Республикасы
Баулы шәһәр Советының
2022 елның 11 апрелендәге
56 номерлы карарына
2нче кушымта

2021 елга "Баулы шәһәре" муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы

(мең сум)

| Атамасы | КВСР | РЗ | ПР | ЦСР | ВР | Касса башкаруы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **«БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** | **802** | | | | | **122 565,1** |
| **Гомумдәүләт сораулары** | **802** | **01** | | | | **12 207,5** |
| **Россия Федерациясе Хөкүмәте, Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимиятнең югары органнары, җирле администрацияләр эшчәнлеге** | **802** | **01** | **04** | | | **6 153,9** |
| Чыгымнарның программалы булмаган юнәлешләре | 802 | 01 | 04 | 99 0 00 00000 | | 6 153,9 |
| Үзәк аппарат | 802 | 01 | 04 | 99 0 00 02040 | | 6 153,9 |
| Дәүләт (муниципаль) органнары, казна учреждениеләре, бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары тарафыннан функцияләр башкаруны тәэмин итү максатларында персоналга түләү чыгымнары | 802 | 01 | 04 | 99 0 00 02040 | 100 | 3 508,6 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 802 | 01 | 04 | 99 0 00 02040 | 200 | 2 635,2 |
| Башка бюджет ассигнованиеләре | 802 | 01 | 04 | 99 0 00 02040 | 800 | 10,1 |
| **Башка гомумдәүләт сораулары** | **802** | **01** | **13** | | | **6 053,6** |
| Чыгымнарның программалы булмаган юнәлешләре | 802 | 01 | 13 | 99 0 00 00000 | | 6 053,6 |
| Оешмалар мөлкәтенә салым һәм җир салымы түләү | 802 | 01 | 13 | 99 0 00 02950 | | 110,9 |
| Башка бюджет ассигнованиеләре | 802 | 01 | 13 | 99 0 00 02950 | 800 | 110,9 |
| Дәүләтнең башка йөкләмәләрен үтәү | 802 | 01 | 13 | 99 0 00 20300 | | 5 933,1 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 802 | 01 | 13 | 99 0 00 20300 | 200 | 5 933,1 |
| Муниципаль хезмәткәрләре иминиятләштерү | 802 | 01 | 13 | 99 0 00 92410 | | 7,0 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 802 | 01 | 13 | 99 0 00 92410 | 200 | 7,0 |
| Муниципаль хезмәткәрләрне диспансерлаштыру | 802 | 01 | 13 | 99 0 00 97071 | | 2,6 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 802 | 01 | 13 | 99 0 00 97071 | 200 | 2,6 |
| **Милли иминлек һәм хокук саклау эшчәнлеге** | **802** | **03** | | | | **383,2** |
| **Гражданнар оборонасы чыгымнары** | **802** | **03** | **09** | | | **233,2** |
| Чыгымнарның программалы булмаган юнәлешләре | 802 | 03 | 09 | 99 0 00 00000 | | 233,2 |
| Икътисадның мобилизацион әзерлеген тәэмин итү чаралары | 802 | 03 | 09 | 99 0 00 22920 | | 233,2 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 802 | 03 | 09 | 99 0 00 22920 | 200 | 233,2 |
| **Милли иминлек һәм хокук саклау өлкәсендә башка мәсьәләләр** | **802** | **03** | **14** | | | **150,0** |
| Чыгымнарның программалы булмаган юнәлешләре | 802 | 03 | 14 | 99 0 00 00000 | | 150,0 |
| Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлеген тәэмин итүче муниципаль хезмәткәрләрне тоту | 802 | 03 | 14 | 99 0 00 22700 | | 150,0 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 802 | 03 | 14 | 99 0 00 22700 | 200 | 150,0 |
| **Илкүләм икътисад** | **802** | **04** | | | | **33 767,2** |
| **Юл хуҗалыгы** | **802** | **04** | **09** | | | **31 095,5** |
| "Татарстан Республикасының иң төзек торак пункты" исеменә республика конкурсында җиңүчеләрне бүләкләү | 802 | 04 | 09 | 04 8 04 14200 | | 440,0 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 802 | 04 | 09 | 04 8 04 14200 | 200 | 270,2 |
| Башка бюджет ассигнованиеләре | 802 | 04 | 09 | 04 8 04 14200 | 800 | 169,8 |
| Чыгымнарның программалы булмаган юнәлешләре | 802 | 04 | 09 | 99 0 00 00000 | | 30 655,5 |
| Шәһәр округлары һәм җирлекләр чикләрендә автомобиль юлларын һәм инженерлык корылмаларын төзекләндерү кысаларында төзү, карап тоту һәм ремонтлау | 802 | 04 | 09 | 99 0 00 78020 | | 30 655,5 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 802 | 04 | 09 | 99 0 00 78020 | 200 | 4 814,3 |
| Капитальные вложения в объекты государственной (муниципальной) собственности | 802 | 04 | 09 | 99 0 00 78020 | 400 | 1 488,7 |
| Башка бюджет ассигнованиеләре | 802 | 04 | 09 | 99 0 00 78020 | 800 | 24 352,5 |
| **Милли икътисад өлкәсендә башка мәсьәләләр** | **802** | **04** | **12** | | | **2 671,7** |
| Чыгымнарның программалы булмаган юнәлешләре | 802 | 04 | 12 | 99 0 00 00000 | | 2 671,7 |
| Җир төзелеше һәм җирдән файдалану чаралары | 802 | 04 | 12 | 99 0 00 73440 | | 2 671,7 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 802 | 04 | 12 | 99 0 00 73440 | 200 | 2 671,7 |
| **Торак-коммуналь хуҗалык** | **802** | **05** | | | | **45 909,5** |
| **Торак хуҗалык** | **802** | **05** | **01** | | | **15 648,9** |
| Чыгымнарның программалы булмаган юнәлешләре | 802 | 05 | 01 | 99 0 00 00000 | | 15 648,9 |
| Төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль берәмлекләр бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар | 802 | 05 | 01 | 99 0 00 25600 | | 7 608,0 |
| Бюджетара трансфертлар | 802 | 05 | 01 | 99 0 00 25600 | 500 | 7 608,0 |
| Күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау буенча республика программасы составына кертелмәгән торак фондына капиталь ремонт | 802 | 05 | 01 | 99 0 00 76030 | | 8 040,9 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 802 | 05 | 01 | 99 0 00 76030 | 200 | 8 040,9 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **Коммуналь хуҗалык** | **802** | **05** | **02** | | | **6 907,5** |
| Коммуналь хуҗалык өлкәсендә чаралар | 802 | 05 | 02 | 99 0 00 75050 | | 6 907,5 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 802 | 05 | 02 | 99 0 00 75050 | 200 | 3 930,5 |
| Башка бюджет ассигнованиеләре | 802 | 05 | 02 | 99 0 00 75050 | 800 | 2 977,0 |
| **Төзекләндерү** | **802** | **05** | **03** | | | **23 353,1** |
| Чыгымнарның программалы булмаган юнәлешләре | 802 | 05 | 03 | 99 0 00 00000 | | 23 353,1 |
| Урамнарны яктырту | 802 | 05 | 03 | 99 0 00 78010 | | 9 547,8 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 802 | 05 | 03 | 99 0 00 78010 | 200 | 5 330,0 |
| Башка бюджет ассигнованиеләре | 802 | 05 | 03 | 99 0 00 78010 | 800 | 4 217,8 |
| Яшелләндерү | 802 | 05 | 03 | 99 0 00 78030 | | 3 445,9 |
| Башка бюджет ассигнованиеләре | 802 | 05 | 03 | 99 0 00 78030 | 800 | 3 445,9 |
| Зиратларны карап тоту | 802 | 05 | 03 | 99 0 00 78040 | | 1 612,7 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 802 | 05 | 03 | 99 0 00 78040 | 200 | 1 612,7 |
| Шәһәр округларын һәм җирлекләрен төзекләндерү буенча башка чаралар | 802 | 05 | 03 | 99 0 00 78050 | | 8 746,7 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 802 | 05 | 03 | 99 0 00 78050 | 200 | 36,2 |
| Башка бюджет ассигнованиеләре | 802 | 05 | 03 | 99 0 00 78050 | 800 | 8 710,5 |
| **Әйләнә-тирә мохитне саклау** | **802** | **06** | | | | **4 315,5** |
| **Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә башка мәсьәләләр** | **802** | **06** | **05** | | | **4 315,5** |
| Чыгымнарның программалы булмаган юнәлешләре | 802 | 06 | 05 | 99 0 00 00000 | | 4 315,5 |
| Табигатьне саклау чаралары | 802 | 06 | 05 | 99 0 00 74460 | | 4 315,5 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 802 | 06 | 05 | 99 0 00 74460 | 200 | 552,5 |
| Башка бюджет ассигнованиеләре | 802 | 06 | 05 | 99 0 00 74460 | 800 | 3 763,0 |
| **Мәдәният һәм кинематография** | **802** | **08** | | | | **162,9** |
| **Мәдәният** | **802** | **08** | **01** | | | **162,9** |
| Чыгымнарның программалы булмаган юнәлешләре | 802 | 08 | 01 | 99 0 00 00000 | | 162,9 |
| Мәдәният өлкәсендә чаралар | 802 | 08 | 01 | 99 0 00 10990 | | 162,9 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 802 | 08 | 01 | 99 0 00 10990 | 200 | 162,9 |
| **Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына гомуми характердагы бюджетара трансфертлар** | **802** | **14** | | | | **25 819,3** |
| **Прочие межбюджетные трансферты общего характера** | **802** | **14** | **03** | | | **25 819,3** |
| Чыгымнарның программалы булмаган юнәлешләре | 802 | 14 | 03 | 99 0 00 00000 | | 25 819,3 |
| Җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәү буенча чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен җирле бюджетларга бюджетара трансфертлар | 802 | 14 | 03 | 99 0 00 25700 | | 25 819,3 |
| Бюджетара трансфертлар | 802 | 14 | 03 | 99 0 00 25700 | 500 | 25 819,3 |
| **Барлыгы:** | | | | | | **122 565,1** |

Татарстан Республикасы
Баулы шәһәр Советының
2022 елның 11 апрелендәге
56 номерлы карарына
3нче кушымта

2021 елгы бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре
һәм бүлекчәләре буенча «Баулы шәһәре» муниципаль
берәмлеге бюджеты чыгымнары

(мең сум)

| **Атама** | **РЗ** | **ПР** | **Касса башкаруы** |
|---|---|---|---|
| **Гомумдәүләт сораулары** | **01** | | **12 207,5** |
| Россия Федерациясе Хөкүмәте, Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимиятнең югары органнары, җирле администрацияләр эшчәнлеге | 01 | 04 | 6 153,9 |
| Башка гомумдәүләт сораулары | 01 | 13 | 6 053,6 |
| **Милли иминлек һәм хокук саклау эшчәнлеге** | **03** | | **383,2** |
| Гражданнар оборонасы чыгымнары | 03 | 09 | 233,2 |
| Милли иминлек һәм хокук саклау өлкәсендә башка мәсьәләләр | 03 | 14 | 150,0 |
| **Илкүләм икътисад** | **04** | | **33 767,2** |
| Юл хуҗалыгы | 04 | 09 | 31 095,5 |
| Милли икътисад өлкәсендә башка мәсьәләләр | 04 | 12 | 2 671,7 |
| **Торак-коммуналь хуҗалык** | **05** | | **45 909,5** |
| Торак хуҗалык | 05 | 01 | 15 648,9 |
| Коммуналь хуҗалык | 05 | 02 | 6 907,5 |
| Төзекләндерү | 05 | 03 | 23 353,1 |
| **Әйләнә-тирә мохитне саклау** | **06** | | **4 315,5** |
| Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә башка мәсьәләләр | 06 | 05 | 4 315,5 |
| **Мәдәният һәм кинематография** | **08** | | **162,9** |
| Мәдәният | 08 | 01 | 162,9 |
| **Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына гомуми характердагы бюджетара трансфертлар** | **14** | | **25 819,3** |
| Гомуми характердагы башка бюджетара трансфертлар | 14 | 03 | 25 819,3 |
| **Барлыгы:** | | | **122 565,1** |

Татарстан Республикасы
Баулы шәһәр Советының
2022 елның 11 апрелендәге
56 номерлы карарына
4нче кушымта

«Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең 2021 елга
бюджет дефицитын финанслау чыганаклары

(мең сум)

| Күрсәткеч атамасы | Бюджет классификациясе коды | | Касса башкаруы |
|---|---|---|---|
| | Керемнәр администраторы | бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары | |
| Барлык чыганаклар | | | -22 937,2 |
| Баулы муниципаль районының финанс-бюджет палатасы | 803 | | -22 937,2 |
| Бюджет чараларын исәпкә алу счетларында калган акчаларны үзгәртү | 803 | 01 05 00 00 00 0000 000 | -22 937,2 |
| Бюджетларның калган акчаларын арттыру | 803 | 01 05 00 00 00 0000 500 | -171 867,2 |
| Бюджетларның калган башка чараларын арттыру | 803 | 01 05 02 00 00 0000 500 | -171 867,2 |
| Бюджетларның калган башка акчаларын арттыру | 803 | 01 05 02 01 00 0000 510 | -171 867,2 |
| Җирлекләр бюджетларының калган башка акчаларын арттыру | 803 | 01 05 02 01 10 0000 510 | -171 867,2 |
| Бюджетларның калган чараларын киметү | 803 | 01 05 00 00 00 0000 600 | 148 930,0 |
| Бюджетларның калган башка чараларын киметү | 803 | 01 05 02 00 00 0000 600 | 148 930,0 |
| Бюджетларның калган башка акчаларын киметү | 803 | 01 05 02 01 00 0000 610 | 148 930,0 |
| Җирлекләр бюджетларының калган башка акчаларын киметү | 803 | 01 05 02 0110 0000 610 | 148 930,0 |

Татарстан Республикасы
Баулы шәһәр Советының
2022 елның 11 апрелендәге
56 номерлы карарына
2нче кушымта

Гражданнарның «2021 елда «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында» Баулы шәһәр Советы карары проекты буенча тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм аның буенча фикер алышуда катнашу
ТӘРТИБЕ

1. «2021 елда «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында» Баулы шәһәр Советы карары проектына тәкъдимнәр Баулы шәһәр Советына түбәндәге адрес буенча язмача рәвештә кертелә: Баулы шәһәре, Куйбышев ур., 20 йорт.

Тәкъдимнәр 2022 елның 21 апреленә кадәр эш көннәрендә 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашуга гаризалар шәхсән яисә почта аша түбәндәге адрес буенча бирелә: 423930, Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20 йорт (конвертка “2021 елда “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында” карар буенча фикер алышу” яисә “ачык тыңлаулар” дигән тамга куеп).

Баулы шәһәр Советының
2021 елның 11.04.2022
56 номерлы карарына
3нче кушымта

«2021 елда «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында» Баулы шәһәр Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар уздыру
ТӘРТИБЕ

1. “2021 елда “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында” Баулы шәһәр Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар (алга таба - ачык тыңлаулар) Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, әлеге Тәртип нигезендә уздырыла.

2. Ачык тыңлаулар уздыру комиссиясенә ачык тыңлаулар уздыру датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча язма гаризалар тапшырган район кешеләре үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнаша ала.

3. Чыгыш ясау катнашу хокукыннан башка ачык тыңлауларда районның барлык кызыксынган халкы катнашырга мөмкин.

4. Катнашучыларны теркәү ачык тыңлаулар башланганчы 1 сәгать алдан башлана.

5. Ачык тыңлауларда Баулы шәһәре мэры яисә аның кушуы буенча муниципаль берәмлекнең башка вазыйфаи заты рәислек итә.

6. Ачык тыңлаулар утырышта катнашучыларга фикер алышына торган мәсьәләнең асылы, тыңлаулар уздыру тәртибе турында хәбәр итә торган рәиснең кереш сүзе белән ачыла.

7. Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне, рекомендацияләрне исәпкә алу өчен, рәис тәкъдиме буенча, җитәкче һәм секретариатның ике әгъзасы составында ачык тыңлаулар секретариаты сайлана.

8. Төп доклад белән эш төркеме әгъзасы чыгыш ясый.

9. Чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашучылар гариза бирү

вакытына бәйле рәвештә чират тәртибендә үз тәкъдимнәрен аргументацияләү өчен чакырыла.

10. Ачык тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары 7 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел. Рәислек итүче рөхсәте белән чыгыш озайтылырга мөмкин, әмма 3 минуттан да артык түгел.

11. Ачык тыңлауларда катнашучылар утырыш тәмамланганнан соң чыгыш ясаучыларга рәис рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы.

12. Ачык тыңлауларда катнашучылар ачык тыңлаулар барышына тыкшынырга, аларны туктатырга һәм аларны үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

13. Ачык тыңлаулар уздырганда тәртип саклау ачык тыңлауларда катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.

14. Катнашучы ачык тыңлаулар уздыру тәртибен бозган очракта, рәис аны утырыш залыннан чыгаруны таләп итәргә хокуклы.

15. Чыгышлар тәмамлангач, рәис ачык тыңлаулар барышында әйтелгән тәкъдимнәрне, киңәшләрне төгәлләштерү өчен ачык тыңлаулар секретариаты җитәкчесенә сүз бирергә мөмкин.

16. Ачык тыңлауларда катнашучыларның барлык искәрмәләре һәм тәкъдимнәре секретариатка язма рәвештә тапшырыла һәм ачык тыңлаулар беркетмәсенә кушып бирелә. Ачык тыңлаулар беркетмәсе рәислек итүче тарафыннан имзалан һәм билгеләнгән тәртиптә Совет материалларында саклана.

17. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә эш төркеме тарафыннан әзерләнә.

18. Ачык тыңлаулар уздыруны оештыру һәм матди-техник тәэмин итү Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советы Аппараты тарафыннан тормышка ашырыла.